СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

6 нчы март, 2024 ел Алабуга шәһәре №329

Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар планы чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2023 елның 15 декабрендәге 301 номерлы карарына ү згәрешләр кертү хакында

Алабуга муниципаль районындагы бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 статьясына таянып, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар планы чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2023 елның 15 декабрендәге 301 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

*1 нче өлештә:*

1 пунктта «3 103 746,9» саннарын «3 130 538,4» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта «3 103 746,9» саннарын «3 207 379,2» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «0,00» саннарын «76 840,8» саннарына алмаштырырга;

*3 нче өлештә:*

1 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны «2024 елга район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» яңа редакциядә бәян итәргә.

2) 3 статьяда:

2 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының фаразлана торган керемнәре күләме» яңа редакциядә бәян итәргә.

3) 5 статьяда:

3 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» яңа редакциядә бәян итәргә;

4 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (АМР

муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;

5 нче кушымтаның 1 нче таблицасын «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;

4) 13 статьяда:

11 нче кушымтаның таблицасын «2024 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар күләме» үзгәрешләр кертелә торган өлешен бәян итәргә;

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджетның икътисади үсеше, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка һәм туризмга ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов